| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2017 Казан ш. № 10-6/кс

2017-2021 елларга «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күп тармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү хезмәтләренә тарифлар билгеләү хакында

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя хасил итү нигезләре һәм тарифларны, өстәмәләрне һәм чик дәрәҗә индексларын җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы карары, Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә тарифларны һәм өстәмәләрне хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2011 елның 15 февралендәге 47 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017-2021 елларга «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күп тармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү хезмәтләренә шушы карарга 1 кушымта нигезендә, календарь буенча бүлеп, тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2017 елның 1 маеннан башлап 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү өлкәсендә «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күп тармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җитештерү программасындагы төп күрсәткечләрне шушы карарның 2 пунктында күрсәтелгән тарифлар гамәлдә булган чорга шушы карарның 2 кушымтасына туры китереп килештерергә.

4. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү хезмәтләренә шушы карарда билгеләнгән тарифлар Татарстан Республикасы

Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренең кулланучылар өчен үтемле булуын ачыклау өчен кулланыла торган криетрияләр системасын билгеләү турында» 2017 елның 27 февралендәге 39 номерлы карары белән расланган коммуналь комплекс оешмалары товарларының һәм хезмәтләренең кулланучылар өчен үтемле булу критерияләренә җавап бирә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.03.2017 № 10-6/кс карарына
1 кушымта

«Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күп тармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә календарь буенча 2017-2021 елларга бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, коммуналь комплекс оешмасының аталышы | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү хезмәтләренә тарифлар, сум/куб м. | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2021 ел | |
| | | 1 майдан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Алабуга муниципаль районы | | | | | | | | | | |
| 1 | «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күп тармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 82,23 | 82,23 | 82,23 | 86,05 | 86,05 | 88,29 | 88,29 | 91,05 | 91,05 | 95,45 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.03.2017 № 10-6/кс карарына
2 кушымта

Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү өлкәсендә «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күп тармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җитештерү программасындагы төп күрсәткечләре

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасының аталышы | Коммуналь комплекс оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | «Торак хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча күп тармаклы җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән, мең куб м.: | Барлыгы | 62,28 | 62,28 | 62,28 | 62,28 | 62,28 |
| | | | Халык | | | | | |
| | | | Бюджет кулланучылары | | | | | |
| | | | Башка төр кулланучылар | 62,28 | 62,28 | 62,28 | 62,28 | 62,28 |
| | | Кирәкле тулай табыш, мең сум (НДС башка) | | 5121,15 | 5265,15 | 5 454,59 | 5 611,07 | 5 832,99 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге